Аксубай муниципаль районы Беловка
авыл жирлеге Советы
423050 Аксубай районы,Яңа Үзи
авылы,
Мәктәп урамы, 7 нче йорт

Совет Беловского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423050 Аксубаевский район,с.Новое
Узеево улица Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru, sovet.belov@mail.ru*

---

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

№7 01.11.2022 ел

«Аксубай муниципаль районының Алексеевка авыл җирлегендә үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ

1. 2022 елның 12 ноябрендә СК бинасында 10 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Аксубай районы, Алексеевка авылы, Зеленая урамы, 21 йорт Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Алексеевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Алексеевка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы-1 нче группа инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган мобилизацияләнгән гражданнарны махсуслаштырылган хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар); җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1.Алексеевка авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
-- Алексеевка торак пункты чикләрендә юл полотносын төзү шул исәптән: грунт күтәрү, грейдлау, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл юлларына таш салу өчен таш сатып алу
- Алексеевка авыл җирлеге торак пункты чикләрендә кышкы юлны карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр һәм җиһазлар алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).
**2.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**
- сууткәргеч челтәрен ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И.Р.Махмутов

СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ